ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
ДРОЖЖАНОВСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЧҮПРӘЛЕ
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

22.11.2022 с.Старое Дрожжаное № 618

Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районы гомуми белем бирү учреждениеләрендә укучыларны туклandыруны оештыру турындагы карарга үзгәрешләр кертү хакында

«Балаларны һәм яшьләрне тәрбияләү һәм укытуны, ял итү һәм сәламәтләндерү оешмаларына санитар-эпидемиологик таләпләр» СП 2.4.3648-20 санитар кагыйдәләрен раслау турында» Россия Федерациясе Баш дәүләт санитария табибының 2020 елның 28 сентябрендәге 28 номерлы карары нигезендә Чүпрәле муниципаль районы Башкарма комитеты КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районы Башкарма комитетының «2022 елда Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районының гомуми белем бирү учреждениеләрендә укучыларны туклandыруны оештыру турында» 2022 елның 02 сентябрендәге 459 номерлы карарына (08.11.2022 ел, № 602 редакциясендә) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

**1.3.1 пунктта** «Россия Федерациясе Кораллы Көчләренә мобилизация буенча хәрби хезмәткә чакырылган гражданнар балаларын» сүзләрен «Россия Федерациясе Кораллы Көчләренә мобилизацияләү буенча хәрби хезмәткә чакырылган гражданнар, хәрби хезмәткәрләр һәм Россия Федерациясе милли гвардиясендә хезмәт итүче затларны, Татарстан Республикасында формалаштырылган «Алга» һәм «Тимер» батальоннарында хәрби хезмәт үтүчеләр, махсус хәрби операция барышында хәрби бурычларны ирекле үтәүче гражданнар балаларын, Татарстан Республикасы буенча Эчке эшләр министрлыгы, Россия Федерациясе Федераль иминлек хезмәтенең Татарстан Республикасы буенча идарәсе хезмәткәрләре, махсус хәрби операция үткәрү зонасына командировкага җибәрелгән, шулай ук махсус хәрби операциядә катнашу нәтиҗәсендә һәлак булган (үлгән) гражданнарның югарыда күрсәтелгән категорияле балаларына» сүзләренә алмаштырырга;

Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районы муниципаль бюджет гомуми белем бирү учреждениеләре укучыларын кайнар аш белән тәэмин итүне

оештыру тәртибе турында **нигезләмәнең 1 пунктындагы беренче абзацында** өстәмә социаль ярдәмгә (карарга кушымта итеп) мохтаҗлар исемлеге

«- Россия Федерациясе Кораллы Көчләренә мобилизация буенча хәрби хезмәткә чакырылган гражданнарның балаларын» түбәндәге яңа редакциядә бәян итәргә:

«махсус хәрби операциядә катнашучы гражданнарның балаларын һәм махсус хәрби операциядә катнашу нәтиҗәсендә һәлак булган (үлгән) гражданнарның балаларын.».

2. Әлеге карар рәсми басылып чыгарга тиеш.

Башкарма комитет
Җитәкчесе

Д.А. Сатдинов